ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

19.02.2025 № 226

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру дәүләт функциясен Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкару буенча административ регламентны раслау турында» 2021 елның 3 февралендәге 139 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Прокуратурасының 2025 елның 04 февралендәге 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру дәүләт функциясен Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкару буенча административ регламентны раслау турында» 2021 елның 3 февралендәге 139 номерлы карары (3 июнь, 2021 ел, N 496 карар редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру дәүләт функциясен Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкару буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. I бүлекнең 1.7 пунктындагы 12 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«12) квартал саен төзүчедән күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән төзүче тарафыннан төзелеш проектларын, шартнамәләр буенча үз йөкләмәләрен, төзелеш проектының җыелма тупланма базасын гамәлгә ашыруның якынча графикларын, шулай ук Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә төзелгән арадаш һәм еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын башкару турында хисап, һәм, төзүче 2011 елның 6 декабрендәге 402-ФЗ номерлы «Бухгалтерлык хисабы турында» Федераль законның 18 статьясында каралган бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын дәүләт мәгълүмат ресурсын (алга таба - бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсы) формалаштыру максатларында мондый хисаплылыкны тапшыру бурычыннан азат ителгән очракта, еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын алырга. Әгәр төзүче бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгының дәүләт мәгълүмат ресурсын формалаштыру максатларында еллык бухгалтерлык (финанс) хисабын тапшыра икән, контрольлек итүче орган мондый хисапны ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, әлеге дәүләт мәгълүмат ресурсыннан ала;»

1.2. I бүлекнең 1.10 пунктындагы 7 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. III бүлектәге 1 нче таблицаның 2 пунктындагы 2.14 пунктчасында «өч һәм аннан күбрәк блоктан торган блоклы төзелеш торак йортларын,» сүзләрен «блокланган төзелеш йортларын (әгәр мондый йортлар саны бер рәттә өч һәм аннан да күбрәк тәшкил итсә)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин